**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 ел **Чирмешән авылы** № 362

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарны исәпкә алу тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының торак урыннарга мохтаҗ аз керемле гражданнарга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 14 апрелендәге 176 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексының 85 һәм 89 статьяларына һәм «Россия Федерациясе Торак кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 233-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Торак кодексының 57 һәм 95 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 14 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ дип танылган аз керемле гражданнарны исәпкә алу тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының торак урыннарга мохтаҗ аз керемле гражданнарга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 14 апрелендәге 176 номерлы карарына (2024 елның 7 августындагы 279 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8.3 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар яисә билгеләнгән тәртиптә

бердәнбер торак урыннары яшәү өчен яраксыз дип танылган һәм ремонтланырга яки реконструкцияләнергә тиеш булмаган торак урыннарның милекчеләре булган гражданнарга. Әлеге пунктта күрсәтелгән торак урыннар милекчеләренә социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар чираттан тыш бирелә, әгәр федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә милек хокукындагы торак урыны урнашкан яисә мондый торак урыны булган күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген киләчәктә мондый торак урынын алу максатларында дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу турында карар кабул ителмәгән булса;».

1.2. 1.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә «9.1. Гражданнар, социаль наем шартнамәләре буенча (әгәр Россия Федерациясе Торак кодексында башкасы билгеләнмәгән булса) төзекләндерелгән башка торак урыннары биреп, торак урыннарыннан чыгарылалар, әгәр:

1) торак урын булган йорт сүтелергә тиеш;

2) торак урын дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен шундый торак урын урнашкан яки шундый торак урын булган күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген тартып алуга бәйле рәвештә тартып алынырга тиеш (1.1 пунктчасы 2015 елның 1 апреленнән «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 31 декабрендәге № 499-ФЗ Федераль законы нигезендә үз көченә керә);

3) торак урын торак булмаган урынга күчерелергә тиеш;

4) торак урын яшәү өчен яраксыз дип табылган;

5) йортка капиталь ремонт ясау яисә реконструкция ясау нәтиҗәсендә торак урын сакланып кала алмый яисә аның гомуми мәйданы кими, нәтиҗәдә анда яшәүче яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары торак урыннарга мохтаҗ дип танылырга мөмкин, йә гомуми мәйданы артачак, нәтиҗәдә биләгән торак урынның гомуми мәйданы гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган нормадан шактый артып китәчәк;

6) торак урын «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» Федераль закон нигезендә дини оешмага тапшырылырга тиеш.

1.3. 10.9 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә «10.9. Гражданнарга әлеге Нигезләмәнең 12.1-12.8 пунктчаларында каралган нигезләр буенча күчерелүгә бәйле рәвештә бирелә торган башка торак урын социаль наем шартнамәсе буенча тиешле торак пункт шартларына карата төзекләндерелгән, гомуми мәйданы, элек биләгән торак урыны буенча бертигез булган булырга, билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә һәм әлеге торак пункт чикләрендә булырга тиеш. Мондый бирелә торган торак урын гражданнарның язма ризалыгы белән Россия Федерациясе субъектының элек биләгән торак урыны урнашкан башка торак пункты чикләрендә булырга мөмкин. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торучы яисә шушы исәптә торырга хокуклы аз керемле гражданнарга торак урыннар бирү нормалары буенча бирелә. Федераль законда, Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актында каралган очракларда Россия Федерациясе Торак кодексының 86 һәм 87_2 статьяларында каралган нигезләр буенча күчерелүче гражданнарга яллаучының һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының, шул исәптән вакытлыча булмаган гаилә әгъзаларының язма

ризалыгы белән социаль торак шартнамәсе буенча башка төзекләндерелгән торак урын бирү урынына наем акчалата түләнергә мөмкин, аның күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый акты яисә Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов